**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2022 Балык Бистәсе штп. № 334пи

Балык Бистәсе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын караган һәм тәрбияләгән өчен түләүдән азат итү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 21.09.2022 ел, №647 Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ , «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, №273-ФЗ Федераль законнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында” 20.10.2022 №1122, “Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында” 20.10.2022 №1122карарына үзгәрешләр кертү хакында" 14.11.2022 №1213 карарлары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең һәм затларның, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарның, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнарның, махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак (вафат) булган югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнарның гаиләләреннән булган ата-аналарны ( законлы вәкилләрне) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларын караган һәм тәрбияләгән өчен түләүдән азат итәргә.

2. "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесенә тәкъдим итәргә:

2.1. 1 пунктта күрсәтелгән ташламаны мәгариф оешмасында тәрбияләнүченең ата-анасын (законлы вәкилен) өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакыру турында хәрби комиссариат белешмәсе нигезендә бирергә;

2.2. өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны кире кайтарган очракта ташламаларның гамәлдә булуын тикшереп тору максатында хәрби комиссариат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тотарга.

3.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең һәм затларның, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарның, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнарның, махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак (вафат) булган югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнарның гаиләләреннән булган Балык Бистәсе муниципаль районының мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карауны финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар 2022 елның 7 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе И.М. Садыйковка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.Л. Исланов